

21 ноябрь конне Лəмберə район vзəгендə балалар язучысы Шəvкəт Галиевнын тууына 90 ел тулу унаеннан «Шəvкəт абыйга багышлыйбыз» дип исемлəнгəн əдəби кичə узды. Кичəгə районнын биш мəктəбеннəн татар теле һəм əдəбияты укытучылары һəм Шəvкəт Галиевнен ижатын кызыксынып ойрəнvче 5-7 класс укучылары килделəр.
Очрашу Лəмберə районы мəгариф бvлеге методисты Линара Аллям кызы Муртазинанын язучынын 90-еллык юбилее белəн котлау сvзлəре белəн башланды. Линара Аллəм кызы кичəбезне татар халкында гимнга əйлəнгəн Габдулла Тукайнын «И, туган тел» жыры белəн башлап жибəрергə чакырды. Черемиш топ мəктəбенен татар теле һəм əдəбияты укытучысы Фазия Фəрит кызы Боярова язучынын тормыш юлы турындагы презентация белəн таныштырды. Татар Тавла топ мəктəбенен татар теле һəм əдəбияты укытучысы Альфия Фатих кызы Муртазина белəн Аксен урта мəктəбенен татар теле һəм əдəбият укытучысы Əлфия Шəйхетден кызы Абдюшева яшь тамашачыларга язучынын ижаты, анын тормышыннан кызыклы фактлар сойлəделəр.
Укучылар да сынатмады, Шəvкəт абыйларынын ижатын яратып ойрə-нvлəрен, шигырьлəрен яттан белvлəрен кvрсəттелəр. Черемиш топ мəктəбенен 5нче класс укучылары: Мансурова Илнара, Зинченко Алина, Тимкаев Зульфат шагыйрьнен шигыре буенча язылган «Утыр əле яннарыма» жырын жырладылар, «Онытылган» шигырен сəхнəлəштереп, «Колегез» һəм «Рəхмəтлəр турында» шигырьлəрен матур итеп яттан сойлəделəр.
Татар Тавла топ мəктəбенен 5нче класс укучысы Муртазина Самиранын «Пəрəмəч» шигырен яттан сəнгатьле укуы беркемне дə битараф калдырмады. Ə Аксен урта мəктəбенен 7нче класс укучысы Фетхуллова Айша vзенен ин яраткан «Акыл теше кемгə чыга» шигырен укыды. Шул ук мəктəпнен 6нчы класс укучысы «Куян физзарядка ясый» шигырен бик кызыклы итеп сойлəде. Кырви урта мəктəбенен укучылары Янгличева Сумия, Байбикова Гvзəл, Абушаев Алим барыбызны да «Шəвəли» китабыннан берничə шигырьне яттан сойлəvлəре белəн шатландырдылар. Пензятка ур-та мəктəбенен 5нче сыйныф укучысы Бикмурзина Зохрə, 6нчы сыйныфлы Григорькина Эльвина бик матур итеп Боек Ватан сугышына багышланган шигырьлəрне яттан сойлəделəр.
Балалар белəн бик кызыклы викторина Пензятка урта мəктəбенен татар теле һəм əдəбияты укытучысы Рауза Мукатдəс кызы Юмаева уздырды. Һəр укучы Шəvкəт Галиевнен ижатын яхшы белvлəрен кvрсəттелəр. Ə шулай да Самира Муртазина викторинада ин актив булды.
Кырви урта мəктəбенен татар теле һəм əдəбияты укытучысы Луиза Низаметдин кызы Смакаева «Рус телен белv яхшы, туган телне белv тиеш» дигəн темага укучылар белəн

әнгәмә оештырды. Укучылар бик теләп катнаштылар.
Бәйрәм бvләкләрсез була алмый бит. Безнен бәйрәм дә бvләкләр тарату белән тәмамланды. Укучылар барысы да Линара Алләм кызы тарафыннан кызыклы китаплар һәм татлы бvләкләр белән бvләкләнде.

**Фазия Боярова**